ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СИЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д. 1, с. Смак-Корса,
Арский муниципальный район, 422025

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СЕЖЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Мәктәп урамы, 1 йорт, Курса Почмак авылы,
Арча муниципаль районы, 422025

Тел. (84366)53-2-36, факс (84366)53-2-36. E-mail: Smk.Ars@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«20» август 2025 ел** **№ 64**

**Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 25 гыйнварындагы “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмешле лампаларның туплану урыннарын билгеләү турында” 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 14 мартындагы “Дәүләт экология мониторингы (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингы) турында Нигезләмәне раслау хакында” 300 номерлы карарына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 25 гыйнварындагы “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмешле лампаларның туплану урыннарын билгеләү турында” 1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 һәм 5 пунктларны 5 һәм 6 пунктлар дип санарга;

1.2. Түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

«4. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Сеҗе авыл җирлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмешле лампалар туплану урынының (урыннарының) урнашуы турында әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында мондый урыннарның урнашуы турында мәгълүмат урнаштыру юлы белән кулланучыларга хәбәр итәргә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Сеҗе авыл җирлеге башлыгы Р.В.Хамидуллин